МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

__16.03.2016___ г.Казань №_____70______

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга яраштыру максатында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелү өчен теркәлгән үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289нчы, 2015 елның 19 мартындагы 134нче, 2015 елның 3 июлендәге 317нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән бергә) (алга таба – Административ регламент)

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

3. Административ реформа мәсьәләләре идарәсенең лицензияләү бүлегенә әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве уздырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне министр урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

Министр А.А.Здунов

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган
16.03.2016__ №_70__

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл һәм төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Административ регламентның 2 бүлегендә:

2.4 пунктының «Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац белән тулыландырырга:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату каралмаган.»;

2.5 пунктының атамасын «гариза бирүче тапшырырга тиешле» дигән сүзләрдән соң «, гариза бирүче тарафыннан алыну ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

2.5 пунктының «Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораган гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формадагысы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлгән документлар кәгазь документ формасында гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (юлланырга) мөмкин:

ышаныч язуы нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче махсус зат тарафыннан;

почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу турында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат белән.

Гариза һәм аңа теркәлгән документлар шулай ук электрон документ формасында, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелып, гомуми кулланыштагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы аша тапшырылырга (юлланырга) мөмкин.»;

2.6 пунктының «Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны тапшыру тәртибе һәм алу ысуллары әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела.»;

2.14 пункты атамасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтү урыннарына, шул исәптән күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына туры китерелүен тәэмин итүгә, әлеге хезмәт күрсәтүләр тәртибе турында визуаль, текст формасындагы һәм мультимедиа мәгълүматлар белән бизәү һәм аларны урнаштыруга карата таләпләр»;

2.14 пунктының «Стандарт таләбенең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгынны сүндерү системасы, һаваны суыту-сафландыру системасы, документларны тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат яктыртылган стендлар белән җиһазландырыган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына каршылыкларсыз керүе тәэмин ителә (бинага керү-чыгу юлларының, бина эчендә йөрүнең уңайлылыгы).

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текст формасындагы һәм мультимедиа мәгълүматлар, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләре дә күз уңында тотылып, гариза бирүчеләр өчен уңайлы урында урнаштырыла.

Гавами урын Татарстан Республикасының Дәүләт интегральләшкән телекоммуникацияләр системасына кушылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән җиһазландырыла.»;

Административ регламентның 3 бүлегендә:

3.3.1 пунктчасында «электрон имза белән имзаланган электрон документның» сүзләрен «лицензиягә дәгъва кылучының көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән имзаланган электрон документларның (электрон документлар пакетының)» сүзләренә алыштырырга;

3.3.2 пунктчасының дүртенче абзацын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: «почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу турында хәбәр беркетелгән заказлы хат яисә лицензиягә дәгъва кылучы үзе сайлаганча лицензия бирүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында лицензиягә дәгъва кылучының мондый күчермәне алуын һәм әлеге документның җиткерелүен раслауны тәэмин итә торган ысул белән аңа юллануы»;

3.3.3 пунктчасының җиденче абзацында «яисә электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында» сүзләрен «яисә лицензиягә дәгъва кылучы үзе сайлаганча лицензия бирүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында лицензиягә дәгъва кылучының мондый күчермәне алуын һәм әлеге документның җиткерелүен раслауны тәэмин итә торган ысул белән» сүзләренә алыштырырга;

3.3.9 пунктчасының дүртенче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән» сүзләренә алыштырырга һәм

абзацны: «мондый хәбәрнең җиткерелүен һәм лицензиягә дәгъва кылучының аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән» сүзләре белән тулыландырырга;

3.3.13 пунктчасының өченче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән» сүзләренә алыштырырга һәм абзацны: «мондый хәбәрнең җиткерелүен һәм лицензиягә дәгъва кылучының аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән» сүзләре белән тулыландырырга;

3.4.1 пунктчасында «электрон имза белән имзаланган электрон документның» сүзләрен «лицензиатның, аның хокуклы варисының яисә федераль законнарда каралган башка затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документларның» сүзләренә алыштырырга;

3.4.3 пунктчасының бишенче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән, әлеге хәбәрнең җиткерелүен һәм лицензиягә дәгъва кылучының аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән» сүзләренә алыштырырга;

3.5.1 пунктчасында «электрон имза белән имзаланган электрон документның» сүзләрен «лицензиатның, аның хокуклы варисының яисә федераль законнарда каралган башка затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документларның» сүзләренә алыштырырга;

3.5.3 пунктчасының бишенче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән, әлеге хәбәрнең җиткерелүен һәм лицензиягә дәгъва кылучының аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән» сүзләренә алыштырырга;

3.6.1 пунктчасында «электрон имза белән имзаланган электрон документның» сүзләрен «лицензиатның, аның хокуклы варисының яисә федераль законнарда каралган башка затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документларның» сүзләренә алыштырырга;

3.7.1 пунктчасында «электрон имза белән имзаланган электрон документның» сүзләрен «лицензиатның, аның хокуклы варисының яисә федераль законнарда каралган башка затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документларның» сүзләренә алыштырырга;

3.7.7 пунктчасының дүртенче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән, әлеге хәбәрнең җиткерелүен һәм лицензиягә дәгъва кылучының аны алуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән» сүзләренә алыштырырга;

3.8.1 пунктчасының дүртенче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән» сүзләренә алыштырырга;

3.8.6 пунктчасының дүртенче абзацында «электрон имза белән» сүзләрен «көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән» сүзләренә алыштырырга.